**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлеге составына керүче Әлши торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча**

**КАРАР**

**13 ноябрь 2024 ел.** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Әлши авыл җирлегенең Әлши авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Әлши авылында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзүгә, ремонтлауга, карап тотуга; торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, Әлши авылында килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү?) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2024 елның 13 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучылар исемлегенә 426 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 258 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 254 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлеге составына керүче Әлши авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Әлши авыл җирлегенең Әлши авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Әлши авылында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзүгә, ремонтлауга, карап тотуга; торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, Әлши авылында килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү?) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Әлши авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Әлши авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: ___________ В.Г.Михайлов

Әлши авыл җирлеге
башлыгы ___________________ В.Г.Михайлов